ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, , 423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы, 37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
№7 21.05.2024

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Бәйрәкәтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын һәм схемасын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы, 1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»гы 89-ФЗ санлы Федераль законның 13.4 маддәсе, 2018 елның 31 августындагы «Каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында»гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1039 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

- №1 кушымтага ярашлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын.

- 2 кушымтага ярашлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары схемасын.

2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 1 июлендәге «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестрын һәм схемасын раслау турында»гы 17 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге электрон адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле

үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге электрон адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әhлиева

1 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Бәйрәкәтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары реестры

| Контейнер мәйданчыгы адресы | п. 2.2. СанПиН 2.17.3550-19 туры киләме Әйе/юк | Контейнер мәйданчыгындагы контейнерлар саны, аларның күләме һәм материалы (металл, пластик) | Наличие у капка контейнерлары, капкачны ачу механизмы (педальләр) Әйе/юк | Тиешле керү юллары булу, япма тибы (асфальт, бетон, туфрак һ. б.) | Контейнер мәйданчыгын каплау төре (бетон, асфальт һ. б.) | Контейнер мәйданчыгының коймасы, материалы, биеклеге | Контейнер мәйдаенчыгы мәйданы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Көрәш-Бүләк авылы, Мәктәп урамы | әйе | Саны:4 данә Күләме:0,75 Материал : металл | юк | асфальт | бетон | Коймаланган: әйе Материал: сетка Биеклеге: 2 м | 4 $м^2$ |
| Бәйрәкәтамак авылы, Яңа урам | әйе | Саны:5данә Күләме:0,75 Материал : металл | юк | асфальт | бетон | Коймаланган: әйе Материал: сетка Биеклеге: 2 м | 5 $м^2$ |
| Бәйрәкәтамак авылы, Батыр Шәрипов урамы | әйе | Саны:4 данә Күләме:0,75 Материал : металл | юк | Вак ком-таш | бетон | Коймаланган: әйе Материал: сетка Биеклеге: 2 м | 4 $м^2$ |
| Подгорный бистәсе, Үзәк урам | әйе | Саны:5 данә Күләме:0,75 Материал : металл | юк | асфальт | бетон | Коймаланган: әйе Материал: сетка Биеклеге: 2 м | 5 $м^2$ |
| Подгорный бистәсе, Бакча урамы | әйе | Саны:5 данә Күләме:0,75 Материал : металл | юк | грунт | бетон | Коймаланган: әйе Материал: сетка Биеклеге: 2 м | 5 $м^2$ |
| Подгорный бистәсе, Нагорная урамы | йәе | Саны:4 данә Күләме:0,75 Материал : металл | юк | Вак ком-таш | бетон | Коймаланган: әйе Материал: сетка Биеклеге: 2 м | 4 $м^2$ |

2 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Бәйрәкәтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары схемасы





Нагорная ул.
Нагорная ул.
Подгорный
Центральная ул.
Новая ул.
Зелёная ул.
Тихая ул.
Медицинская ул.
Садовая ул.
Восточная ул.
Южная ул.
Почта № 423966
Воинам ВОВ
ФАП
Дом культуры
Детский сад Радуга
Строительный цех